

Тормышнын торле этапларын vтеп, яшь буынны тәрбияләvдә фидакарь, батыр хезмәте белән халык рәхмәтен, ихтирамын казанып, бvгенге зур эш нәтижәләренә ирешкән олуг йорәкле шәхес – Сания Спартак кызы Саляева.
Ул Рузаевка районы Татар Пешлә туган авылы урта мәктәбендә белем алганнан сон, укытучы булу теләге белән, Казан дәvләт педагогия институтынын тарих-филология факультетына укырга керә. Вузны тәмамлаган белгеч туган авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты буенча якташлары балаларына белем бирә башлый. Үтә тырыш, максатына ирешvчән булуы Сания Спартак кызына туган теле фәнен укытуда югары vрләр яуларга ярдәм итә. Анын укучылары ел саен фән олимпиадаларынын муниципаль, республика, тобәкара, халыкара олимпиадаларында, ижади конкурсларда бvген дә жинvчеләр. Укытучылык вазифасын башкару остенә авыл халкы белән тыгыз элемтәдә эшләргә, торле чараларында катнашырга туры килә ана. Гаиләдә - яраткан әни, мәктәптә - хормәтле укытучы булу бик жинел булмагандыр. Сынатмый ул, нинди генә эшкә кушсалар да жиренә житкереп башкара.
Сания Спартаковна Саляева Мордовия кvләмендә бvген дә зур тәжрибәле, эрудицияле, талантлы педагог. Яшь укытучыларга да, олкән яшьтәгеләргә дә ул vрнәк, эш тәжрибәсен алар белән теләп уртаклаша, аларга методик ярдәм кvрсәтә. Ботенроссия кысаларында vткән чараларда даими эш тәжрибәсе белән уртаклашып килә. Шулай, 2014 елда Ботенроссия укытучылары съездында эш тәжрибәсе белән уртаклаша һәм ирешкән унышларын бәяләп «Почетный работник общего образования» дигән олы бvләк белән бvләкләнә. Ә 2019 елда vткән «Заман укытучысына – заманча таләпләр» Ботенроссия мәгариф һәм фән хезмәткәрләре пленар утырышында «Мәгарифтәге казанышлары очен» медале тапшырыла. Хезмәтенә югары бәя бирелеп, кvпләгән Мактау грамоталары белән бvләкләнде.
26 июльдә Сания Спартак кызы Саляева матур гына 60-яшьлек гомер бәйрәмен – Юбилеен билгеләп vтәчәк. Аны ихластан Мордовия татар теле һәм әдәбияты

укытучылары, Насыровлар, Юмаевлар котлап изге теләкләрен юллыйлар.
Хөрмәтле, яраткан Сания Спартак кызы!
Киләчәктә тагын да зуррак vрләр яуларга, балаларынын, оныкларынын игелеген кvреп тынычлыкта, сәламәтлектә озын гомер кичеререгә язсын. Авыр һәм мактаулы хезмәтендә зур уңышлар, соенеч-шатлыклар кvп булсын.